МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.05.2016 г.Казань № 117/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2016 № 1/2-пр боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 12 октябрендәге “2014-2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрен мелиорацияләүне үстерү” федераль максатчан программасы турында” № 922 карарын үтәү максатында, б о е р ы к б и р ә м:

1.Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2016 № 1/2-пр боерыгына (16.02.2016 № 15/2-пр, от 13.04.2016 № 73/2-пр, от 21.03.2016 № 45/2-пр, от 11.05.2016 № 99/2-пр, от 27.05.2016 № 114/2-пр боерыклары төзәтмәләрендә) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.17 пунктчасы белән тулыландырырга:

“1.17. 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына гомуми һәм шәхси кулланылыштагы мелиоратив системаларын һәм аерым урнашкан гидротехника корылмаларын төзү, үзгәртеп кору, техник яктан яңадан коралландыру өчен чыгымнарны каплау өлешендә “2014-2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрен мелиорацияләүне үстерү” федераль максатчан программасы буенча субсидияләр бирү тәртибе (17 кушымта)”.

1. Боерыкка карата 17 кушымтаны шушы Боерыкка карата кушымтага туры китереп, яңа эчтәлегендә бәян итәргә.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының 15.01.2016 № 1/2-пр (ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының 30.05.2016 № 117/2-пр боерыгы төзәтмәсендә) 17 кушымта

2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына гомуми һәм шәхси кулланылыштагы мелиоратив системаларын һәм аерым урнашкан гидротехника корылмаларын төзү, үзгәртеп кору, техник яктан яңадан коралландыру өчен чыгымнарны каплау өлешендә “2014-2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрен мелиорацияләүне үстерү” федераль максатчан программасы буенча субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) гомуми һәм шәхси кулланылыштагы мелиоратив системаларын һәм аерым урнашкан гидротехника корылмаларын төзү, үзгәртеп кору, техник яктан яңадан коралландыру өчен чыгымнарны каплау өлешендә “2014-2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрен мелиорацияләүне үстерү” федераль максатчан программасы (алга таба – Программа) буенча субсидияләр бирү тәртибен билгели.

2. Авыл хуҗалыгында җитештерүнең һәм туфракларның продуктлылылыгын һәм уңдырышлылыгын комплекслы мелиораңия чаралары белән арттыру субсидияләрне бирү максаты булып тора.

3. Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен субсидия алуга сайлап алу критерийлары булып үсемчелек продукңиясен җитештерү тора.

4. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милегендә яки билгеләнгән тәртиптә аларга файдалануга тапшырылган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр (алга таба – объектлар) булу субсидияләрн бирүнең шартлары булып тора.

5. Субсидияләр хуҗалыклар һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары кысаларында, аталган объектларга карата проект һәм эзләнү эшләрен алып баруга һәм (яки) проект документларын әзерләүгә бәйле чыгымнардан гайре, гомуми һәм шәхси кулланылыштагы мелиоратив системаларын һәм аерым урнашкан гидротехника корылмаларын төзү, үзгәртеп кору, техник яктан яңадан коралландыру өчен чыгымнарны каплау өчен Программага кертелгән объектлар төзелә башлаганнан бирле башкарылган эшләрнең күләменнән 50 процентыннан артмаган күләмдә исәпләнеп бирелә.

6. Арбитраж суды тарафыннан субсидияләрне алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта, алар (алучылар) эш кузгатылган көнне бу хакта язмача рәвештә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына хәбәр итәргә бурычлы (алга таба - Министрлык).

Арбитраж суды тарафыннан аларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирелми.

7. Субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) хуҗалыклар һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары кысаларында гомуми һәм шәхси кулланылыштагы мелиоратив системаларын һәм аерым урнашкан гидротехника корылмаларын төзү, үзгәртеп кору, техник яктан яңадан коралландыру өчен чыгымнарны каплау өлешендә:

үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза;

объектларны төзү, үзгәртеп кору, торгызу буенча җыелма смета хисапларының күчермәләре;

эшләр башкаруга подряд шартнамәләре;

КС-2 статистик рәвеше буенча эшләрне кабул итү турында акт;

объект төзелеше башланганнан бирле КС-3 статистик рәвеше буенча башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнары турында белешмә;

Министрлык раслый торган рәвештә тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә;

техник күзәтчелек башкаручы “Татарстан Республикасы буенча җирләрне мелиорацияләү һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең чылатыла торган кишәрлекне яки гидротехника корылмасын тапшырылган мелиоратив җайланманың техник сыйфатламалары һәм чылату системасының аерым төзелмәләренең урнашу схемалары буенча төзү яки торгызу мөмкинлеге турында бәяләмәсе.

Заказчы һәм техник күзәтчелек хезмәтен (төзелеш контрольлеген) тәэмин итү өчен чыгымнарны финанслау федераль бюджет акчалары хисабыннан программага бюджет финанславыннан бирелгән сумманың 2,14 проценты күләмендә гамәлгә ашырыла;

б) хуҗалыклар һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары кысаларында гомуми һәм шәхси кулланылыштагы мелиоратив системаларын һәм аерым урнашкан гидротехника корылмаларын техник яктан яңадан коралландыруга киткән чыгымнарны каплау өлешендә:

үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза;

мелиоратив техникасын китерү шартнамәсе (2016 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган чорда мелиоратив техника сатып алуны раслый торган);

мелиоратив техниканы китертүгә счет-фактуралар;

2016 елда мелиоратив техниканы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең шәхси акчаларына сатып алганлыкны раслый торган түләү йөкләмәләре;

мелиоратив техникасын китертүгә кабул итеп алу-тапшыру актлары һәм товар накладнойлары;

Министрлык раслый торган рәвештә сатып алынучы мелиоратив техникага киткән чыгымнарны каплау өлешендә белешмә-исәпләмә;

техник күзәтчелек башкаручы “Татарстан Республикасы буенча җирләрне мелиорацияләү һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең чылатыла торган кишәрлекне яки гидротехника корылмасын тапшырылган мелиоратив җайланманың техник сыйфатламалары һәм чылату системасының аерым төзелмәләренең урнашу схемалары буенча төзү яки торгызу мөмкинлеге турында бәяләмәсе.

Заказчы һәм техник күзәтчелек хезмәтен (төзелеш контрольлеген) тәэмин итү өчен чыгымнарны финанслау федераль бюджет акчалары хисабыннан программага бюджет финанславыннан бирелгән сумманың 2,14 проценты күләмендә гамәлгә ашырыла.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан таныклана.

8. Министерлык:

а) субсидияләр бирү турында гаризаларны кергән көнендә журналда терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш;

б) шушы Тәртинең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерәләр. Документларны карап тикшерү вакыты гаризаны теркәгән көннән башлап 5 эш көне тәшкил итә.

9. Субсидияләр гаризаларны тапшыру тәртибендә бюджет акчалары лимиты кысаларында бирелә.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларны тулы күләмдә тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган белешмәләр булу;

бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту очрагында, Министрлык 8 пунктта күрсәтелгән вакыт узганнан соң эш көннәрендә хисаплана торган 5 көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә ел дәвамында шикаять кылынырга мөмкин.

10. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларга, акча чараларын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә, акча чараларын күчерүне хәл итә.

11. Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

12. Максатларын һәм (яки) шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм (яки) документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 февраленә кадәр, федераль бюджет керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

14. Бюджет акчаларын федераль бюджет керемнәренә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

15. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

16. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен

җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

17. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.